КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 26 февраль г.Казань № 138

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы, 2018 ел, 7 май, 327 нче, 2018 ел, 30 июль, 614 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче, 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы, 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче, 2020 ел, 11 февраль, 87 нче, 2020 ел, 15 май, 392 нче, 2020 ел, 8 август, 666 нчы, 2021 ел, 17 июнь, 467 нче, 2021 ел, 11 август, 700 нче, 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы, 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы, 2022 ел, 7 март, 202 нче, 2022 ел, 17 март, 244 нче, 2022 ел, 29 апрель, 402 нче, 2022 ел, 22 сентябрь, 1029 нчы, 2022 ел, 11 ноябрь, 1196 нчы, 2023 ел, 6 март, 214 нче, 2023 ел, 21 март, 306 нчы, 2023 ел, 17 июль, 851 нче, 2023 ел, 10 октябрь, 1284 нче, 2023 ел, 30 ноябрь, 1536 нчы, 2024 ел, 18 март, 155 нче, 2024 ел, 14 июнь, 427 нче, 2024 ел, 15 ноябрь, 1011 нче, 2024 ел, 10 декабрь, 1127 нче, 2025 ел, 7 март, 138 нче, 2025 ел, 23 апрель, 261 нче, 2025 ел, 15 май, 327 нче, 2025 ел, 3 июнь, 401 нче, 2025 ел, 17 июнь, 438 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 4 217,3 мең сумлык айлык фонды белән 174 берәмлек итеп билгеләргә, шулардан:

40 берәмлек – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 1 179,3 мең сумлык айлык фонды белән үзәк аппарат хезмәткәрләре, шул исәптән:

федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 437,4 мең сумлык айлык фонды белән 18 берәмлек;

Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 741,9 мең сумлык айлык фонды белән 22 берәмлек;

134 берәмлек – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 3 038,0 мең сумлык айлык фонды белән территориаль бүлекчәләр хезмәткәрләре, шул исәптән:

федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 505,6 мең сумлык айлык фонды белән 18 берәмлек;

Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 2 532,4 мең сумлык айлык фонды белән 116 берәмлек.».

2. Бу карарның гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                   А.В.Песошин